ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.12.2020 № 1292

2021 елның 1 яртыеллыгына торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак бина元арны карап торкан өчен түләү күләме турында, социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәре җирлекләрендә 2021 елның 1 яртыеллыгына торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап торкан өчен түләү күләме турында, социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына

караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен расларга (1 нче кушымта).

2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елның 2 яртыеллыгына торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында, социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2020 елның 30 июнендәге 543/2 номерлы карары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш һәм гамәлдә булу чоры 2021 елның 1 гыйнварыннан башлап барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф.Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“ 1292 ” 24.12.2020 ел
карарына 1 нче кушымта

## Социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту буенча түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы торак урыннар хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга күрсәтелгән хезмәт төрләре буенча 2021 елның 1 гыйнварыннан түләү күләме

| **№ т/б** | **Хезмәтнең исеме** | **Түләү алынучы үлчәнеш берәмлеге (айга), сум.** | **Күрсәтелгән хезмәтнең үлчәнеш берәмлеге буенча тариф (сумнарда)** |
|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2021 ел. 30.06.2021 ел. |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 3,86 |
| **2** | Уртак милек составына керүче гомуми файдалану урыннарын, шулай ук җир участогын санитар яктан карап тоту, шул исәптән: | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | **24,29** |
| | -гомуми файдалану урыннарын җыештыру; | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 3,44 |
| | - йорт яны территориясен җыештыру | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 4,62 |
| | - чүп чыгару торбасын карап тоту; | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 3,25 |
| | - дератизация | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 0,18 |
| | - торак биналарның конструктив элементларын агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 2,73 |

| №<br>т/б | Хезмәтнең исеме | Түләү алынучы үлчәнеш берәмлеге (айга), сум. | Күрсәтелгән хезмәтнең үлчәнеш берәмлеге буенча тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2021 ел.<br>30.06.2021 ел. |
| | - йорт эчен су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 2,29 |
| | - үзәк җылытуның йорт эчендәге челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 2,29 |
| | - йорт эчендәге электр челтәрләренә һәм җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 1,02 |
| | -йорт эчендәге газ белән тәэмин итү челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм аларны ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 0,28 |
| | - йорт эчендәге вентиляцион (җилләтү) каналларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 0,26 |
| | -1 каттан башлап лифтларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 3,93 |
| 3 | Ггомумйорт газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 21,53 |
| 4 | Наем өчен түләү (яллаучылар өчен) | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 6,11 |